Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Азалаковского сельского поселения
Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге башкарма
комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
13.08.2025 ел

КАРАР
№ 14

Азалак авыл җирлеге Башкарма комитетының 05.04.2023 ел, № 8 «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Азалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашкан урыны турында мәгълүмат бирү турында»карарына үзгәрешләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең "Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турындагы нигезләмәне раслау хакында" 14.03.2024 No 300 карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Азалак авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Азалак авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Азалак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашкан урыны турында мәгълүмат бирү турында» 05.04.2023 ел, № 8 карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

Карарның 4 пунктына түбәндәге эчтәлеклеҗөмлә өстәргә:

«Кулланучыларга терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында мәгълүмат бирү әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Азалак авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе

И.Г.абдулгазизов